**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә Африка дуңгыз чумасы барлыкка килү һәм таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә чикләү чаралары кертү турында

Чувашия Республикасы Порецкий районының Напольное авылы территориясендә терлекләрнең Африка дуңгыз чумасы белән чирләве ачыклануга бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы территориясенә Африка дуңгыз чумасының үтеп керүен һәм таралуын булдырмау максатларында, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә куркыныч янаган икенче зона территориясендә Африка дуңгыз чумасы барлыкка килү һәм таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә чикләү чаралары кертергә.

2. Куркыныч янаган икенче зонага Татарстан Республикасының Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч районнары территорияләре керә дип билгеләргә.

3. Куркыныч янаган икенче зона территориясендә чикләү чаралары гамәлдә вакытта түбәндәгеләр тыела:

базарларда, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Дуңгыз асрау хуҗалыкларының, шулай ук дуңгыз чалуны, дуңгызчылык продуктларын эшкәртү һәм саклауны башкара торган оешмаларның зоосанитария статусын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 23 июлендәге 258 номерлы боерыгы нигезендә III һәм IV компартментларга караучы оешмалар җитештергән дуңгызчылык продукциясеннән тыш, дуңгызлар һәм дуңгызчылык продуктлары сату;

хайваннарны күчерү һәм туплау белән бәйле ярминкәләр, күргәзмәләр, башка чаралар үткәрү;

дуңгызларны хуҗалыкларга һәм торак пунктларга (йортларга) кертү (транспортта алып керү);

дуңгызларны көтүгә чыгару;

элемтә бүлекләренең хайваннардан җитештерелгән продуктлар һәм чимал салынган посылкаларны гражданнардан кабул итүе;

дуңгыз үләксәләрен һәм алардан алынган патологияле материалларны ветеринария лабораторияләренә почта аша җибәрү.

4. СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы Баш ветеринария идарәсенең 1980 елның 21 ноябрендә расланган Африка дуңгыз чумасы барлыкка килүне кисәтү һәм аны бетерү буенча инструкциясендә каралган чаралар уздырылганнан соң 30 көн үткәч, чикләү чараларының гамәле туктатылырга тиеш дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Африка дуңгыз чумасының куркыныч янаган икенче зона территориясендә барлыкка килүен һәм таралуын булдырмау буенча чикләү чаралары планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 24 август
№ ПУ-734